**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Аксар авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

**№38** **28.07.2021ел.**

**"Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Аксар авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында» 2014 елның 08 февралендәге 136 номерлы Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон,2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән расланган Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, Зәй муниципаль районының Аксар авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Аксар авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1."Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Аксар авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында» 2014 елның 08 февралендәге 136 номерлы Зәй муниципаль районы Аксар авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.14 статьяның 1 өлешендә:

1) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) Россия Федерациясе гражданлыгы, аның нигезендә чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокук бирә торган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгы (подданство) туктатылу турында язмача рәвештәмуниципаль хезмәткәргә бу хакта билгеле булган көнне, әмма Россия Федерациясе гражданлыгы яисәчит ил гражданлыгы (подданство) туктатылган көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә;»;

2) түбәндәгеэчтәлекле 9.1 пунктынөстәргә:

«9.1) яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә)чит ил гражданлыгы

(подданствосы) алу яисә гражданның чит ил дәүләте территориясендә даимияшәү хокукын раслаучы башка документ алуы турында муниципаль хезмәткәргә бу хакта билгеле булган көндә, әмма чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) алган яисә чит ил территориясендә гражданның даими яшәү хокукын раслаучы башка документ алган көннән башлап биш көннән дә соңга калмыйча хәбәритәргә;»;

1.2.15статьяның 1 өлешендә:

а) 6 пунктнытүбәндәгередакциядәбәянитәргә:

«6) Россия Федерациясе гражданлыгы яисә аның нигезендә чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокук бирә торган Россия Федерациясе халыкарашартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгы туктатылу;»;

б) 7 пунктны түбәндәге редакциядә бәя нитәргә:

«7) әгәр Россия Федерациясенең халыкарашарт намәсендә башкасы каралмаган булса, чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) яисә чит ил территориясендә гражданның даими яшәү хокукын раслый торган паспорты яки башка документыбулу;»;

1.3.24 статьяның 1 өлешендәге 2 пунктыүзкөченюгалткандиптанырга.

2. Карарны авыл җирлегенеңмәгълүматстендларында, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU), Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Совет рәисе** **Ю.И.Гильманов**